**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

20.05.2016 Яр Чаллы № 1946

«Сабантуй гүзәле-2016» район конкурсын үткәрү турында

Татар халкының традицион мәдәниятен саклап калу һәм үстерү, эстетик тәрбия бирүгә һәм яшьләрнең иҗади сәләтләрен үстерүгә ярдәм итү максатыннан

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2016 елның 26 маенда Иске Абдул авыл җирлегендә «Сабантуй гүзәле - 2016» район конкурсы уздырырга.
2. «Тукай муниципаль районы мәдәният һәм ял үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе акчалары хисабына чыгымнар сметасын расларга (1 кушымта).
3. «Сабантуй гүзәле-2016» район конкурсы нигезләмәсен расларга (2 кушымта).
4. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе 

Р.В. Асылгәрәев